Яңа Кармәт авыл җирлеге башкарма комитеты
Аксубай муниципаль районы
Татарстан Республикасы

Карар

№3 2021 елның 9 нче ноябре

“Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлегенең Яңа Кармәт авыл җирлегендә халык җыены үткәрү турында”

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елның № 131 - ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының “Яңа Кармәт авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында” 2019 елның 5 ноябрендәге 98 номерлы карарына таянып.
Карар итте:
1. Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлеге Яңа Кармәт авылында Кызылармия, Тукай, Муса Җәлил урамнарында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын 2021 елның 16 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта билгеләргә.
2. Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлеге Яңа Кармәт авылында Жданова, Карл Маркс, Зеленая урамнарында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын 2021 елның 23 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта билгеләргә.
3.Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
3.1 ."2022 елда Аксубай муниципаль районының Яңа Кармәт авыл җирлеге Яңа Кармәт авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булмаган һәр кешедән, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә килешәсезме:
1) Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
- Яңа Кармәт авылы Жданов, Карл Маркс, Тукай, Кызыл армия, Зеленая урамнарына таш һәм ташлы грунт сатып алу;
-Яңа Кармәт авылы эчендәге юлларны кышкы чорда карап тоту, Муса Җәлил, Жданов, Тукай, Кызылармия, Карл Маркс, Зеленая урамнарын кардан чистарту буенча килешү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү.
2) Җирләү урыннарын карап тоту һәм ритуаль хезмәтләр оештыру
- Яңа Кармәт авылы зиратында агач кисү килешүе буенча хезмәт өчен түләү

"ӘЙЕ"            " ЮК"          "ТЫЕЛЫП КАЛДЫ"

3. Җыеннар үткәрү урыны-ТР, Аксубай районы, Яңа Кармәт авылы, Муса Җәлил урамы, 15а йорт адресы буенча урнашкан Яңа Кармәт авыл мәдәният йорты .
4. Җыенны оештыру һәм үткәрү өчен җаваплылыкны Яңа Кармәт авыл җирлеге башкарма комитетына йөкләргә.
5. Әлеге карарны Яңа Кармәт авыл җирлегенең рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча бастырырга: http://aksubaevo.tatar.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә
6. Әлеге карар кабул ителгән көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районының
Яңа Кармәт авыл җирлеге башлыгы                    И. Р. Шакиров

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ "АКСУБАЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН" СОВЕТ НОВОКИРЕМЕТСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ